# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**2002 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында**

**1 статья**. 2002 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын керемнәр буенча - 35 409 904 мең сум (утыз биш миллиард дүрт йөз тугыз миллион тугыз йөз дүрт мең сум) күләмендә һәм чыгымнар буенча 37 631 932 мең сум (утыз җиде миллиард алты йөз утыз бер миллион тугыз йөз утыз ике мең сум) күләмендә расларга.

2002 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 2 222 028 мең сум күләмендә билгеләргә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2002 елда кредит оешмаларыннан алынган кредитларны; Татарстан Республикасы исеменнән чыгарылучы кыйммәтле кәгазьләрне урнаштырудан алынган акчаларны; автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым, транспорт чаралары хуҗаларыннан салым буенча әлеге Закон нигезендә расланган фараз билгеләнешләреннән Татарстан Республикасының республика бюджетын үтәгәндә чынлыкта артыграк алынган керемнәрне, Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге мөлкәтне сатудан керемнәрне Татарстан Республикасы Республика бюджеты кытлыгын каплау өчен җибәрергә тиеш.

**2 статья.** 2002 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты керемнәре гамәлдәге законнар нигезендә түбәндәгеләр исәбеннән барлыкка килә дип билгеләргә:

- оешмалар табышына салымның бер өлеше;
- физик затларның керемнәренә салымның бер өлеше;
- предприятиеләр мөлкәтенә салымның бер олеше;
-уен бизнесына салым - Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән минималь ставкалардан тыш исәпләп чыгарылган салым суммасының 50 проценты күләмендә;
- Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелә торган азык-төлек чималыннан ясалган чимал этил спиртына, азык-төлек чималыннан ясалган этил спиртына, эчә торган спиртка, спиртлы эремәләргә, аракыга

һәм ликер-аракы эчемлекләренә акцизлар - керемнәрнең 50 проценты күләмендә;

- Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелә торган сырага, тәмәке әйберләренә, ювелир әйберләргә, коньякка, шампан шәрабенә (уенчак шәрабкә), натураль шәрабкә, башка алкогольле эчемлекләргә акцизлар - керемнәрнең 100 проценты күләмендә;

- Россия Федерациясе законнары нигезендә лицензия һәм теркәү җыемнары;

- чит ил акчаларын һәм чит ил валютасында белдерелгән түләү документларын сатып алуга салым - Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән нормативлар буенча, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерү өчен;

- җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән нормативлар буенча бер мәртәбә һәм даими алынучы түләүләр;

- углеводород чималы рәвешендә файдалы казылмалар чыгарган өчен Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына Россия Федерациясе законнары нигезендә кертелергә тиешле салым;

- су объектларыннан файдаланган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнүче түләүнең бер өлеше;

- Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән нормативлар буенча сатудан салым;

- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән нормативлар буенча җир салымы һәм җир өчен аренда түләве;

- эшчәнлекнең аерым бер төрләре өчен йөкләнгән керемгә оешмалар түли торган берләшкән салым, Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына күчерелергә тиешле салым суммасының 50 проценты күләмендә;

- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән ставкалар нигезендә берләшкән социаль салым буенча түләүләрнең бер өлеше;

- автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым - керемнәрнең 100 проценты күләмендә;

- автотранспорт чаралары хуҗаларыннан салым - керемнәрнең 100 проценты күләмендә;

- федераль бюджеттан күрсәтелгән финанс ярдәменең барлык торләре;

- максатчыл бюджет фондлары акчалары;

- салымнар түләгәннән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә бюджетка башка мәҗбүри түләүләрдән соң дәүләт унитар предприятиеләре табышыннан бүлеп бирелгән акчалар;

- Татарстан Республикасының республика бюджетына кертелергә тиешле башка керемнәр.

Татарстан Республикасының республика бюджеты керемнәренә 2001 ел өчен исәп-хисап ясау буенча салым түләүчеләрдән һәм җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр, минераль-чимал базасын

торгызуга бүлеп бирелгән акчалар буенча 2002 елның 1 гыйнварена җыелган бурычны каплау исәбенә керүче акчалар, шулай ук әлеге салымнарны бүлү буенча 2002 елның 1 гыйнварена кадәр гамәлдә булган нормативлар нигезендә күрсәтелгән салымнарны вакытында түләмәгән өчен штрафлар һәм пенялар керә, дип билгеләргә.

**3 статья.** Татарстан Республикасының республика бюджеты керемнәрендә автомобиль транспорты чараларын сатып алуга салым, автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым, минераль-чимал базасын торгызуга кертемнәр буенча 2001 елның 1 гыйнварена җыелган бурычларны һәм Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фондына түләүләр буенча 2002 елның 1 гыйнварена җыелган бурычларны каплау исәбенә салым түләүчеләрдән кергән акчалар, шулай ук элек Татарстан Республикасында Юллар фондына, Татарстан Республикасының Минераль ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына кертү өлешендә шушы салымнарны вакытында түләмәгән өчен штрафлар һәм пенялар, Татарстан Республикасының «Янгын куркынычсызлыгы» дәүләт максатчыл бюджет фондына түләүләр буенча 2001 елның 1 гыйнварена барлыкка килгән бурычларны каплау исәбенә салым түләүчеләрдән Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фондына кергән түләүләр, шулай ук Татарстан Республикасының «Янгын куркынычсызлыгы» дәүләт максатчыл бюджет фондына күрсәтелгән түләүләрне вакытында кертмәгән өчен штрафлар һәм пенялар исәпкә алына, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасында Юллар фонды, Татарстан Республикасының Минераль ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды, Бөлгенлеккә төшүне билгеләү һәм финанс ягыннан савыктыруны тәэмин итүнең махсуслаштырылган фонды, Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды, Татарстан Республикасының «Янгын куркынычсызлыгы» дәүләт максатчыл бюджет фонды, элегрәк төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә оешмалар тарафыннан кире кайтарыла торган акчалар 2002 елда Татарстан Республикасының республика бюджеты керемнәренә кертеп исәпләнелә.

**4 статья.** Җир салымы һәм җир өчен аренда түләвенең 2001 елда гамәлдә булган ставкалары 2002 елда, авыл хуҗалыгы җирләреннән гайре, барлык төр җирләр өчен 1,12 коэффициенты белән кулланыла дип, ә авыл хуҗалыгы җирләре өчен 1,68 коэффициенты кулланыла, дип билгеләргә.

2002 елда бюджет системасы дәрәҗәләре буенча җир салымын һәм җир өчен аренда түләвен кертү, җирләрнең төренә карап, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән нормативлар буенча гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

273

2002 елга «Җир өчен түләү турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясының гамәлдә булуын җир салымын максатчыл файдалану өлешеидә туктатып торырга.

**5 статья.** Дәүләт милкендәге җир кишәрлекләрен яки аларны арендалау хокукын гражданнарга һәм юридик затларга сатудан кергән акчалар, җир салымы һәм җир өчен аренда түләве Россия Федерациясенең салым турындагы законнарында билгеләнгән нормативлар нигезендә бюджет системасының дәрәҗәләре буенча исәпләп чыгарыла.

**6 статья.** Әйләнә-тирә табигать мохитенә зарарлы матдәләр чыгарып ташлаган, агызып чыгарган һәм калдыкларны урнаштырган өчен 2001 елда гамәлдә булган түләү 2002 елда 1,18 коэффициенты белән кулланыла, дип билгеләргә.

**7 статья.** Тамырда килеш сатып җибәрелә торган агач өчен түләүнең 2001 елда гамәлдә булган ставкалары 2002 елда 1,12 коэффициенты белән кулланыла, дип билгеләргә.

**8 статья.** Су объектларыннан файдаланган өчен 2001 елда гамәлдә булган түләү ставкасы, түләүчеләрнең категорияләренә карап, 2 коэффициенты белән кулланыла, дип билгеләргә.

Су электр станцияләрен эксплуатацияләүче түләүчеләргә су объектларыннан файдаланган өчен түләү ставкасын эшләп чыгарыла торган электр энергиясенең бер мең киловатт-сәгате өчен 4,0 сум күләмендә билгеләргә.

Су объектларыннан файдаланган өчен Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына кертелергә тиешле түләү, халыкны су белән тәэмин итү максатында су объектларыннан алынган су өчен шәһәрләрнең һәм районнарның бюджетларына тапшырылучы түләүдән гайре, Татарстан Республикасының республика бюджетына кертелә.

**9 статья.** Предприятиеләр милкенә салым ставкасын салым салына торган базаның 2 проценты күләмендә, дип билгеләргә.

2002 елда, реклама һәм эротик характердагы китап һәм матбугат басмаларыннан гайре, массакүләм мәгълүмат чараларын Татарстан Республикасының республика бюджетына кертелүче өлешендә предприятиеләр мөлкәтенә салымнан азат итәргә. Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советларына җирле бюджетларга кертелүче предприятиеләр мөлкәтенә салым өлешендә шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

**10 статья.** 2002 елда, реклама һәм эротик характердагы китап һәм матбугат басмаларыннан гайре, массакүләм мәгълүмат чаралары өчен Татарстан Республикасының республика бюджетына кертелүче өлешендә табышка салым ставкасын 4 процентка киметергә. Татарстан Республикасы шәһәрләренең һәм районнарының халык депутатлары Советларына үзләренең бюджетларына тапшырылучы өлешендә табышка салым ставкасын массакүләм мәгълүмат чаралары өчен киметү хокукын бирергә. Бу чакта бюджетларның барлык дәрәҗәләренә ташламаларның гомуми суммасы табышка салым ставкасының 4 процентыннан артмаска тиеш.

Татарстан Республикасы шәһәрләренең һәм районнарының халык депутатлары Советларына үзләренең бюджетларына тапшырылучы өлешендә табышка салым ставкасын 2002 елда машина төзелеше һәм җиңел сәнәга предприятиеләре өчен килешүләр белән билгеләнгән һәм җирле бюджетларны төзегәндә исәпкә алынган фараз күрсәткечләреннән артыграк алынган җитештерелгән продукция (эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр) составында өстәлгән хакка кертелүче күләмдә иң күбендә 4 процентка киметү хокукын бирергә.

**11 статья.** Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштырудан алынган акчалар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелергә тиеш.

**12 статья.** «Алабуга» ирекле икътисадый зонасы турында» Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән салым түләүчеләр категориясенә Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә торган өлешендә табышка салым, җир салымы, транспорт чаралары хуҗаларыннан салым түләүдән азат итәргә һәм предприятиеләр мөлкәтенә салым ставкасын 0 процент күләмендә билгеләргә.

**13 статья.** 2002 елга Татарстан Республикасының республика бюджетына түбәндәге фондларны берләштерергә:

Татарстан Республикасы ЭЭМ Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фонды;

Республика сырхауханә кассасы;

Шәһәрләрне, районнарны һәм авылларны газлаштыру буенча дәүләт бюджет фонды;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды;

Кече эшкуарлыкка финанс ярдәме күрсәтү буенча Татарстан республика фонды;

Татарстан Республикасының Экология фонды;

Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренең республика фонды (НИОКР).

275

**14 статья.** 2002 елга Татарстан Республикасының республика бюджетына төп чыганаклар буенча керемнәрнең килерен түбәндәге суммаларда исәпкә алырга:

(мең сумнарда)

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Салым керемнәре - барлыгы, шул исәптән: | 15 991 616 |
| | - оешмалар табышына салым | 4 938 165 |
| | - физик затларның керемнәренә салым | 1 790 263 |
| | - уен бизнесына салым | 7 544 |
| | - акцизлар | 1 370 000 |
| | - сатудан салым | 300 000 |
| | - предприятиеләр мөлкәтенә салым | 996 653 |
| | - 2001 ел өчен исәп-хисаплар буенча исәпләп чыгарылган сумма өлешендә җир асты байлыкларыннан файдаланган һәм узган еллардан калган бурычны каплау өчен түләүләр | 110 807 |
| | - углеводород чималы рәвешендә файдалы казылмалар чыгаруга салым | 2 821 000 |
| | - эшчәнлекнең аерым төрләре өчен йөкләнгән керемгә оешмалар түләүче берләшкән салым | 153 300 |
| | - җир салымы | 206 870 |
| | - су объектларыннан файдаланган өчен түләү | 87 990 |
| | - чит ил акчаларын, чит ил валютасында белдерелгән түләү документларын сатып алуга салым | 20 000 |
| | - автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым | 2 994 429 |
| | - автотранспорт чаралары хуҗаларыннан салым | 90 546 |
| | - башка салымнар, җыемнар һәм пошлиналар | 104 049 |
| 2. | Салымнан килмәгән керемнәр - барлыгы, шул исәптән: | 551 580 |
| | - дәүләт милкендәге мөлкәттән яки дәүләт оешмалары эшчәнлегеннән килгән керемнәр | 372 340 |
| | - дәүләт унитар предприятиеләренең салымнар һәм бюджетка башка мәҗбүри түләүләрдән соң калган табышыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә түләүләр | 100 000 |

276

| | | |
|---|---|---|
| | - салымнан килмәгән башка керемнәр, штраф санкцияләренең бер өлеше, китергән зыянны каплау | 79 240 |
| 3. | Компенсацияләрнең федераль фонды акчалары | 871 000 |
| 4. | Максатчыл бюджет фондлары керемнәре - барлыгы, шул исәптән: | 5 730 908 |
| | Татарстан Республикасы ЭЭМ ЮХИДИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фонды | 265 155 |
| | Республика сырхауханә кассасы | 2 002 477 |
| | Татарстан Республикасының Экология фонды | 337 715 |
| | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды | 2 973 661 |
| | Кече эшкуарлыкка финанс ярдәме күрсәтү буенча Татарстан республика фонды | 16 900 |
| | Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренең республика фонды (НИОКР) | 135 000 |
| 5. | Казан шәһәренең 1000 еллыгы буенча махсус программаны да кертеп, «2006 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше» федераль максатчыл программасы | 12 264 800 |

**15 статья.** 2003 елның 1 гыйнварена Татарстан Республикасы дәүләт бурычының иң югары чиген - 6 900 000 мең сум, шул исәптән дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләрнең иң югары чиген 3 650 000 мең сум күләмендә, дип билгеләргә.

2002 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан эмиссияләнә торган республика облигацияләре эмиссиясенең иң югары чиген 1 500 000 мең сум, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты гамәлдәге законнар нигезендә Татарстан Республикасының бурыч йөкләмәләре булган дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен чыгару күләмнәрен, рәвешләрен һәм эмиссияләү ысулларын әлеге статьяның 2 өлешендә билгеләнгән чикләрдә билгеләргә

һәм аларны эмиссияләүне гамәлгә ашырырга, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт бурычының әлеге статьяның беренче өлешендә билгеләнгән иң югары чигеннән артмаслык күләмдә кредит оешмаларының кредитларын җәлеп итәргә хокуклы.

2002 елда Татарстан Республикасы бирә торган гарантияләрнең күләмен 1 000 000 мең сумнан артык булмаган күләмдә билгеләргә.

**16 статья.** 2002 елда җирле бюджетларга салымнар түбәндәге күләмнәрдә кертелә, дип билгеләргә:

- түбәндәгеләрдән гайре, оешмаларның табышына салым - салым салынучы табышның 14,5 проценты күләмендә:

- Азнакай районына һәм шәһәренә - 3,8 процент, Әлмәт районына һәм шәһәренә - 1,7 процент, Баулы районына һәм шәһәренә - 5 процент, Бөгелмә районына һәм шәһәренә - 1,5 процент, Зәй районына һәм шәһәренә - 5,2 процент, Лениногорск районына һәм шәһәренә - 1 процент, Түбән Кама районына һәм шәһәренә - 4 процент, Яңа Чишмә районына - 1 процент, Нурлат районына һәм шәһәренә - 4 процент, Сарман районына - 3,5 процент, Тукай районына - 10,9 процент, Чирмешән районына - 4,2 процент күләмендә;

- уен бизнесына салым Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән минималь ставкалардан тыш исәпләп чыгарылган салым суммасының 50 проценты күләмендә;

- түбәндәгеләрдән тыш, физик затлар керемнәренә салым 100 процент күләмендә:

Азнакай районына һәм шәһәренә - 60 процент, Әлмәт районына һәм шәһәренә - 16 процент, Баулы районына һәм шәһәренә - 54 процент, Бөгелмә районына һәм шәһәренә - 56 процент, Зәй районына һәм шәһәренә - 65 процент, Лениногорск районына һәм шәһәренә - 86 процент, Нурлат районына һәм шәһәренә - 85 процент, Сарман районына - 64 процент, Тукай районына - 95 процент;

- түбәндәгеләрдән тыш, предприятиеләр мөлкәтенә салым 100 процент күләмендә:

Азнакай районына һәм шәһәренә - 50 процент, Әлмәт районына һәм шәһәренә - 50 процент, Баулы районына һәм шәһәренә - 50 процент, Бөгелмә районына һәм шәһәренә - 50 процент, Зәй районына һәм шәһәренә - 50 процент, Лениногорск районына һәм шәһәренә - 50 процент, Түбән Кама районына һәм шәһәренә - 86 процент, Яңа Чишмә районына - 94 процент, Нурлат районына һәм шәһәренә - 50 процент, Сарман районына - 50 процент, Тукай районына - 50 процент, Чирмешән районына - 50 процент;

- физик затларның мөлкәтенә салым 100 процент күләмендә;

- эшчәнлекнең аерым бер төрләре өчен йөкләнгән керемгә оешмалар түләүче берләшкән салым Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына күчерелергә тиешле салым суммасының 50 проценты күләмендә;

278

- кече эшкуарлык субъектлары өчен җыелма керемгә оешмалар түләүче берләшкән салым, Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына кертелергә тиешле өлешендә;

- халыкны су белән тәэмин итү өчен су объектларыннан алынган су өчен түләү;

- 2002 елның 1 гыйнварена кадәр гамәлдә булган бүлү нормативлары нигезендә җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүнең бер өлеше (2001 ел өчен исән-хисап буенча күчерелүче һәм узган еллардан калган бурычны каплау суммалары өлешендә);

- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән нормативлар буенча җир салымы һәм җир өчен аренда түләве.

Авыл торак пунктлары чикләре кысаларындагы җирләр һәм алар карамагына тапшырылган башка җирләр өчен түләүләр җирле үзидарә бюджетларына күчерелә.

**17 статья.** Файдалы казылмалар чыгаруга (моңа углеводород чималы рәвешендә чыгарылган файдалы казылмалар һәм гомумтаралган файдалы казылмалар керми) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән нормативлар буенча Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле салым суммасы җирле бюджетларга тапшырыла.

Гомумтаралган файдалы казылмалар чыгаруга салым суммасы җирле бюджетларга күчерелә.

**18 статья.** Россия Федерациясе Салым кодексының беренче бүлегендәге 116,117,118,124, 125, 126,128,129,129-1, 132, 134 һәм 135-1 статьяларында, шулай ук 120 статьясының 1 һәм 2 пунктларында каралган салым санкцияләре сыйфатында куланылучы акчалата түләтүләр (штрафлар) суммалары шуларның 25 проценты күләмендә - Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм 25 проценты күләмендә җирле бюджетларга күчерелә.

**19 статья.** 2002 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында чыгымнарны финанслау өчен ассигнованиеләрнең гомуми күләмен 37 631 932 мең сум дип билгеләргә һәм бюджет чыгымнарының функциональ классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча шуларны түбәндәге суммаларда җибәрергә:

| Бүлек һәм бүлекчәнең коды | | Барлык сумма |
|---|---|---|
| | 1. Дәүләт идарәсенә һәм җирле үзидарәгә, шул исәптән: | 1 292 283 |
| 0101 | - Татарстан Республикасы Президенты эшчәнлеген тәэмин итүгә | 64 127 |

279

| | | |
|---|---|---|
| 0102 | - дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары эшчәнлегенә | 55 840 |
| 0103 | - башкарма дәүләт хакимияте органнары эшчәнлегенә | 1 150 052 |
| | шул исәптән: | |
| | - Татарстан Республикасының Россия Федерациясе субъектларындагы һәм чит илләрдәге вәкиллекләре эшчәнлегенә | 47 567 |
| 0105 | - гомумдәүләт идарәсенең башка чыгымнарына | 22 264 |
| | 2. Суд хакимиятенә, | 41 864 |
| | шул исәптән: | |
| 0201 | - җәмәгать судьялары эшчәнлеген тәэмин итүгә | 34 600 |
| 0202 | -Татарстан Республикасының Конституция судын тотуга | 7 264 |
| 0501, 0509, 0510 | 3. Хокук саклау эшчәнлегенә һәм дәүләт иминлеген тәэмин итүгә | 751 724 |
| 0601, 0602 | 4. Фундаменталь тикшеренүләр һәм фәнни-техник прогресска ярдәм итүгә | 67 948 |
| | 5. Сәнәгага, энергетикага, төзелешкә, | 36 594 |
| | шул исәптән: | |
| 0701 | - ягулык-энергетика комплексына | 32 594 |
| 0707 | - төзелешкә, архитектурага | 4 000 |
| | 6. Авыл хуҗалыгына һәм балык хуҗалыгына, | 269 853 |
| | шул исәптән: | |
| 0805 | - авыл хуҗалыгы өлкәсендәге башка чараларга, | 269 853 |
| | шулардан: ветеринариягә | 122 206 |
| | 7. Әйләнә-тирә мохитне, табигый байлыкларны саклауга, гидрометеорологиягә, картографиягә һәм геодезиягә, | 200 112 |
| | шул исәптән: | |
| 0902 | - урман ресурсларына | 149 000 |
| 0904 | - гидрометеорологиягә | 1 300 |

280

| | | |
|---|---|---|
| 0906 | - әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау өлкәсендәге башка чыгымнарга | 49 812 |
| | 8.Транспортка, шул исәптән: | 3 343 985 |
| 1001 | - автомобиль транспортына | 118 776 |
| 1002 | - тимер юл транспортына | 77 509 |
| 1004 | - су юлы транспортына | 25 476 |
| 1005 | - һава юлы транспортына | 13 249 |
| 1006 | - юллар хуҗалыгына, | 3 108 975 |
| | шулардан: Кама елгасы аша күпер кичүе салуга | 850 000 |
| | 9. Торак-коммуналь хуҗалыгына, шул исәптән: | 905 126 |
| 1201 | - торак хуҗалыгына (торак фондын һәм социаль-мәдәни өлкә объектларын кабул итүне һәм файдалануга тапшыруны кертеп) | 266 326 |
| 1202, 0707, 1806 | - коммуналь хуҗалыкка | 583 000 |
| 1203 | - коммуналь хуҗалыкның башка структураларына | 55 800 |
| | 10. Гадәттән тыш хәлләрне һәм табигый бәла-казаларны кисәтүгә һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүгә, шул исәптән: | 43 600 |
| 1302 | - гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүгә | 41 600 |
| 1303 | - граждан оборонасына | 2 000 |
| | 11. Мәгарифкә, шул исәптән: | 493 579 |
| 1402 | - гомуми белемгә | 40 561 |
| 1404 | - урта һөнәр белеменә | 159 474 |
| 1405 | - кадрларны кабат әзерләүгә һәм квалификацияләрен күтәрүгә | 14 780 |
| 1406 | - югары һөнәр белеменә | 50 085 |
| 1407 | - мәгариф өлкәсендәге башка чыгымнарга, | 228 679 |
| | шулардан: балалар һәм яшүсмерләр арасында физик культура һәм спорт эшен үстерүгә | 66 000 |

| | | |
|---|---|---|
| | 12. Мәдәнияткә, сәнгатькә һәм кинематографиягә, шул исәптән: | 414 257 |
| 1501 | - мәдәнияткә һәм сәнгатькә | 391 147 |
| | шулардан: Татарстан Республикасының китапханә эшен үстерү программасын гамәлгә ашыруга | 7 000 |
| 1502 | - кинематографиягә | 23110 |
| | 13. Массакүләм мәгълүмат чараларына, | 249356 |
| | шул исәптән: | |
| 1601 | - телевидениегә һәм радиотапшыруларга | 112662 |
| 1602 | - вакытлы матбугатка һәм нәшриятләргә | 133854 |
| 1602 | -башка массакүләм мәгълүмат чараларына | 2 840 |
| | 14. Сәламәтлек саклауга һәм физик культурага, | 5 068331 |
| | шул исәптән: | |
| 1701 | - сәламәтлек саклауга, | 4 846288 |
| | шулардан: эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүенә түләүләргә | 3 380200 |
| 1702 | - санитария-эпидемиология күзәтчелегенә | 50000 |
| 1703 | - физик культурага һәм спортка | 172043 |
| | 15. Социаль сәясәткә, | 815775 |
| | шул исәптән: | |
| 1801 | - социаль тәэминат учреждениеләренә, | 285578 |
| | шулардан: социаль-медицина экспертизасы хезмәтенә | 40289 |
| 1802 | - социаль ярдәмгә, | 53590 |
| | шулардан: балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерү кампаниясе гамәлләрен финанслауга | 53590 |
| 1803 | - яшьләр сәясәтенә, | 26627 |
| | шулардан: сәләтле балаларга һәм талантлы яшьләргә ярдәм итү өчен | 6500 |
| 1806 | - социаль сәясәт өлкәсендәге башка гамәлләргә, | 449980 |
| | шулардан: халыкны эш белән тәэмин итү программаларын гамәлгә ашыруга | 79250 |

282

| | | |
|---|---|---|
| тиешле бүлекчәләр буенча | 16. «Татарстан балалары» республика программасын гамәлгә ашыруга | 25000 |
| тиешле бүлекчәләр буенча | 17.«Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруга | 8910 |
| тиешле бүлекчәләр буенча | 18. «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруга | 29184 |
| тиешле бүлекчәләр буенча | 19. Татарстан Республикасында наркотик чараларны явыз ниятләрдә куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча комплекслы республика программасын гамәлгә ашыруга | 55000 |
| 1900 | 20. Дәүләт бурычына хезмәт күрсәтүгә | 100000 |
| | 21. Башка дәрәҗәләрдәге бюджетларга финанс ярдәме күрсәтүгә, шул исәптән: | 3233751 |
| 2101 | - район һәм шәһәр бюджетларына дотация бирүгә | 958806 |
| 2101 | - берләшкән социаль салым түләвен исәпкә алып, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү өчен район һәм шәһәр бюджетларына субвенцияләргә | 2274945 |
| | 22. Башка чыгымнарга, шул исәптән: | 954700 |
| 3001 | - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондына | 750000 |
| 3002 | - Татарстан Республикасы халык депутатларының һәм Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларының киткәннәре урынына яңаларын сайлауны уздыруга | 1000 |

283

| | | |
|---|---|---|
| 3004 | - Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясен тотуга | 3318 |
| 3004 | - 2002 елда Бөтенроссия халык санын исәпкә алуга әзерлек эшләре алып баруга | 1763 |
| 3004 | - кече эшкуарлыкка ярдәм итүгә (кире кайтарып бирү нигезендә), | 100000 |
| | шулардан: халыкның художество промыселларын һәм һөнәрләрен саклап калуга һәм үстерүгә | 5000 |
| 3004 | - башка чыгымнарга | 98619 |
| тиешле бүлекчәләр буенча | 23. Инвестиция проектларын финанслау өчен максатчыл чыгымнар | 364292 |
| | 24. Компенсацияләрнең федераль фонды, шул исәптән: | 871000 |
| 1806 | - социаль сәясәт өлкәсендәге башка гамәлләргә, | 644882 |
| | шулардан: «Балалары булган гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» Федераль законны гамәлгә ашыру өчен субвенция | 554215 |
| | - «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законны гамәлгә ашыру өчен субсидияләр | 90667 |
| 2101 | - «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законны гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга субсидияләр | 226118 |
| тиешле бүлекчәләр буенча | 25. Казан шәһәренең 1000 еллыгы буенча кече программаны да кертеп, «2006 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше» федераль максатчыл программага | 12264800 |
| | 26. Максатчыл бюджет фондлары чыгымнары - барлыгы, шул исәптән: | 5730908 |

284

| | | |
|---|---|---|
| 3130 | - Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фонды | 265155 |
| 3130 | - Республика сырхауханә кассасы | 2002477 |
| 3130 | - Татарстан Республикасы Экология фонды | 337715 |
| 3130 | - Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды | 2973661 |
| 3130 | - Кече эшкуарлыкка финанс ярдәме күрсәтү Татарстан республика фонды | 16900 |
| 3130 | - Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренең (НИОКР) республика фонды | 135000 |

**20 статья.** 2002 елда дәүләт хакимиятен гамәлгә ашыру өчен чыгымнарны 1 292 2 83 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

түбәндәгеләрнең эшчәнлеген финанслау өчен чыгымнар:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының | 64127 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, аның Аппаратының, даими нигездә эшләүче халык депутатларының | 45882 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларына депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны кайтару өчен | 546 |
| Закон проектларын эшләүгә һәм экспертизалауга бәйле чыгымнарга | 1000 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләрен үткәрүгә бәйле чыгымнарга | 2190 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Парламент контроле комитетына | 6222 |
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына | 34720 |

285

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы министрлыкларына, дәүләт комитетларына, ведомстволарына һәм аларның территория органнарына, Россия Федерациясе субъектларындагы һәм чит илләрдәге Татарстан Республикасы вәкиллекләренә, | 1076332 |

шул исәптән:

2002 елга Россия Федерациясе субъектларында Татарстан Республикасы вәкиллекләрен тотуга 22922 мең сум, шулардан:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиллегенә | 18063 |
| Татарстан Республикасының Свердлов өлкәсендәге даими вәкиллегенә | 1876 |
| Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәрендәге һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиллегенә | 2983 |

2002 елга Татарстан Республикасының халыкара эшчәнлеген гамәлгә ашыруга 24645 мең сум, шулардан:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Үзбәкстан Республикасындагы даими вәкиллегенә | 1669 |
| Татарстан Республикасының Азәрбайҗан Республикасындагы даими вәкиллегенә | 1157 |
| Татарстан Республикасының Казахстан Республикасындагы вәкаләтле вәкиллегенә | 1747 |
| Татарстан Республикасының Франциядәге вәкаләтле вәкиллегенә | 6070 |
| Татарстан Республикасының Төркиядәге вәкаләтле вәкиллегенә | 4432 |
| Татарстан Республикасының Вашингтон шәһәрендәге (АКШ) даими вәкиллегенә | 3163 |

286

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Чехия һәм Словакия республикаларындагы даими вәкиллегенә | 2882 |
| Татарстан Республикасының Кипр Республикасындагы вәкиллегенә | 1868 |
| Татарстан Республикасының Финляндия Республикасындагы сәүдә-икътисад буенча вәкиленә | 1657 |
| «Дәүләт хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чыгымнарына | 35000 |
| «Татарстан Республикасы алдында аерым казанышлары булган гражданнарның дәүләт пенсиясенә өстәмә турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чыгымнарына | 4000 |
| Архив учреждениеләрен финанслау чыгымнарына | 18236 |
| Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның аппаратын тоту эшчәнлеген финанслау чыгымнарына | 4028 |

**21 статья.** Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары белән төп эш итүчеләр, аларда бюджет кредитлары алучыларга Татарстан Республикасы исеменнән таләпләр кую хокукларын беркетеп, кайтарып бирү һәм түләүле нигездә юридик затларга Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары һәм бюджеттан тыш акчалар исәбеннән элек үзләре биргән бюджет кредитларын Татарстан Республикасының республика бюджетына кайтарып бирүне тәэмин итәләр, дип билгеләргә.

Бөлгенлек (банкротлык) турындагы законнар белән җайга салына торган мөнәсәбәтләрдә бюджет кредитларын кайтарып бирү турында Татарстан Республикасы таләпләре, шулай ук алардан файдаланган өчен түләү кредиторның акча йөкләмәләре буенча таләпләре була һәм алар законнарда билгеләнгән чиратлылык тәртибендә канәгатьләндерелергә тиеш, дип билгеләргә.

**22 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2002 елда дәүләт хезмәткәрләренең һәм бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм оешмалары хезмәткәрләренең санын, Татарстан Республикасы Министрлар

287

Кабинеты карарлары белән яңа кертелә торган объектлардагы хезмәткәрләр санынннан гайре, арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятеиең җирле органнарына 2002 елда дәүләт хезмәткәрләренең һәм бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм оешмалары хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар чыгармаска тәкъдим итәргә.

**23 статья.** Бюджетта каралган гамәлләрне өзлексез финанслауны тәэмин итү максатларында 2002 елда Татарстан Республикасының республика бюджетыннан район һәм шәһәр бюджетларына 3 459 869 мең сум күләмендә дотацияләр, субвенцияләр һәм субсидияләр бүлеп бирергә, шул исәптән:

(мең сумнарда)

| Районнар һәм шәһәрләр исеме | Дотация | Берләшкән социаль салымны исәпкә алып, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакын өлешчә түләүгә субвенция | Компенсацияләрнең федераль фондыннан субсидияләр |
|---|---|---|---|
| Әгерҗе районы | 12 956 | 51 824 | 652 |
| Азнакай районы һәм шәһәре | | | 2 459 |
| Аксубай районы | 919 | 3 678 | 259 |
| Актаныш районы | 5 309 | 69 589 | 398 |
| Алексеевск районы | 65 289 | 68 340 | 567 |
| Әлки районы | 45 879 | 74 675 | 376 |
| Әлмәт районы һәм шәһәре | | | 7 499 |
| Апас районы | 20 535 | 69 781 | 333 |
| Арча районы | 53 573 | 112 731 | 1 754 |
| Әтнә районы | 36 210 | 38 516 | 257 |
| Баулы районы һәм шәһәре | | | 1785 |
| Балтач районы | 35 722 | 90 201 | 855 |
| Бөгелмә районы һәм шәһәре | | | 5 412 |
| Буа районы һәм шәһәре | 33 262 | 110 105 | 1 508 |
| Югары Ослан районы | 20 360 | 51 735 | 294 |
| Биектау районы | 10 221 | 40 885 | 1 474 |
| Чүпрәле районы | 15 846 | 81 968 | 332 |
| Алабуга районы һәм шәһәре | 25 082 | 100 328 | 5 278 |
| Зәй районы һәм шәһәре | | | 3 405 |
| Зеленодол районы һәм шәһәре | 53 856 | 215 426 | 6 462 |
| Кайбыч районы | 12 226 | 40 576 | 127 |
| Кама Тамагы районы | 27 447 | 50 611 | 334 |

288

| | | | |
|---|---|---|---|
| Кукмара районы | 79 425 | 112 190 | 1 875 |
| Лаеш районы | 10 562 | 42 249 | 400 |
| Лениногорск районы һәм шәһәре | | | 2 389 |
| Мамадыш районы | 75 876 | 123 378 | 2 321 |
| Менделеев районы | 1 698 | 6 790 | 741 |
| Минзәлә районы | 31 367 | 71 675 | 456 |
| Мөслим районы | 17 545 | 58 052 | 327 |
| Түбән Кама районы һәм шәһәре | | | 14 453 |
| Яна Чишмә районы | | | 121 |
| Нурлат районы һәм шәһәре | | | 3 007 |
| Питрәч районы | 32 810 | 66 926 | 1 221 |
| Балык Бистәсе районы | 26 014 | 79 566 | 283 |
| Саба районы | 42 103 | 76 102 | 1 249 |
| Сарман районы | | | 986 |
| Спас районы | 47 738 | 70 087 | 789 |
| Тәтеш районы | 34 865 | 76 870 | 1 183 |
| Тукай районы | | | 225 |
| Теләче районы | 13 577 | 51 908 | 300 |
| Чирмешән районы | | | 353 |
| Чистай районы һәм шәһәре | 70 534 | 168 183 | 6 075 |
| Ютазы районы | | | 436 |
| Чаллы шәһәре | | | 30 121 |
| Казан шәһәре | | | 114 987 |
| Барлыгы: | 958 806 | 2 274 945 | 226 118 |

Федераль фондтан компенсацияләр керемнәре суммасы үзгәргәндә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты субсидияләр күләмнәренә төзәтмәләр кертергә хокуклы.

Дотация бүлеп бирү Татарстан Республикасы республика бюджеты керем өлешенең фактик үтәлешен исәпкә алып башкарыла.

Татарстан Республикасының республика бюджетыннан субвенция, бердәм социаль салым түләүне исәпкә алып, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә өлешчә хезмәт хакы түләү өчен бирелә һәм бары тик максатчыл билгеләнеш буенча гына файдаланыла.

**24 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, «2006 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше» федераль максатчыл программасының дәүләт заказчысы белән килештереп, гамәлләрне финанслауны югарыдагы программада каралган күләмнәрдә һәм юнәлешләрдә әлеге Законга 1, 2 иче кушымталар нигезендә гамәлгә ашырырга тиеш.

**25 статья.** 2002 елда җирле үзидарә бюджетлары түбәндәге салым керемнәре хисабына төзелә, дип билгеләргә:

- физик затлар керемнәренә салымның бер өлеше;
- Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән, тиешле җирле үзидарә территориясендә алына торган дәүләт пошлинасы;
- җирле үзидарә территориясендәге түләүчеләрдән су объектларыннан файдаланган өчен алына торган түләү;
- мирас итеп алу һәм бүләк итү тәртибендә күчә торган мөлкәткә салым;
- җирле үзидарә гамәлгә ашырыла торган территорияләр чикләре кысаларындагы җирләр өчен һәм алар карамагына тапшырылган башка җирләр өчен җир салымы;
- милицияне тоту, территорияне төзекләндерү өчен, мәгариф ихтыяҗлары һәм башка максатлар өчен гражданнардан һәм оешмалардан максатчыл җыемнар;
- физик затларның тиешле җирле үзидарә территориясендә булган мөлкәтенә салым;
- гамәлдәге законнар нигезендә алына торган башка салымнар һәм җыемнар.

Әгәр югарыда күрсәтелгән чыганаклардан керә торган акчалар суммасы минималь социаль стандартлардан һәм нормалардан түбәнрәк булса, халык депутатларының җирле Советларына үз бюджетларында җирле үзидарә органнарына дотацияләр һәм субвенцияләр бирүне күздә тотуны тәкъдим итәргә.

**26 статья.** 2002 елда Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы ЮХИДИ идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге фондына (алга таба - Юл хәрәкәте иминлеге фонды) күчерелә торган штрафлар күләмнәрен - Россия Федерациясе законнары нигезендә, ә автотранспорт чараларына дәүләт техник тикшерүе үткәргән өчен һәм дәүләт теркәү тамгалары биргән өчен Юл хәрәкәте иминлеге фондына күчерелә торган җыемнар ставкаларын законнар нигезендә билгеләргә.

2002 елга Юл хәрәкәте иминлеге фонды бюджетын керемнәр буенча - 265 155 мец сум күләмендә, чыгымнар буенча 265 155 мең сум күләмендә расларга.

2002 елда Юл хәрәкәте иминлеге фонды бюджеты керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән барлыкка килә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Автотранспорт чараларына дәүләт техник тикшерүе үткәргән өчен җыемнар | 84 644 |
| Дәүләт теркәү тамгалары биргән өчен җыемнар | 104691 |

290

| | |
|---|---|
| Башка керемнәр | 75820 |

2002 елда Юл хәрәкәте иминлеге фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Юл хәрәкәте иминлеге фондының шәһәр һәм район бүлекләренә бүлеп бирү өчен | 32 158 |
| Юл хәрәкәте иминлеге гамәлләренә | 32 158 |
| Дәүләт техник тикшерүе станцияләрен үстерүгә һәм тотуга бүлеп бирү өчен | 72 433 |
| Дәүләт теркәү тамгалары чыгару буенча эксплуатация чыгымнарына бүлеп бирү өчен | 89 590 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына бүлеп бирү өчен | 13 258 |
| Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына бүлеп бирү өчен | 13 258 |
| Башка чыгымнарга | 12 300 |

**27 статья.** 2002 елга Республика сырхауханә кассасы бюджетын керемнәр буенча - 5 382 677 мең сум, чыгымнар буенча 5 382 677 мең сум күләмендә расларга.

2002 елда Республика сырхауханә кассасы акчаларының бюджет керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән барлыкка килә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән ставкалар буенча берләшкән социаль салым түләүләренең бер өлеше | 1 982 000 |
| Эшчәнлекнең аерым бер төрләре өчен йөкләнгән керемгә закон белән билгеләнгән берләшкән салым түләүләренең бер өлеше | 20 477 |
| Эшләмәүче халыкка Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларыннан мәҗбүри медицина иминләштерүенә кертемнәр | 3 380 200 |

2002 елда Республика сырхауханә кассасы акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| ММИнең территориаль программасын финанслауга - барлыгы, | 5 352 227 |
| шул исәптән: | |
| - мәҗбүри медицина иминләштерүенең территориаль программасын үтәүгә, | 5 263 576 |
| шулардан: медицина хезмәте күрсәтүләргә түләү фондына, | 4 910 082 |
| шул исәптән: | |
| - профессиональ патология республика үзәген финанслауга | 5 000 |
| - ММИнең территориаль программасы кысаларында сырхауханә кассалары эшчәнлегенең финанс шартларын тигезләүгә | 302 051 |
| - нормалаштырылган иминләштерү запасына | 51 443 |
| - территориаль фонд тарафыннан идарәчел функцияләрне үтәүгә, | 88 651 |
| шулардан: | |
| - территория сырхауханә кассаларын тотуга | 72 100 |
| - РСК функцияләрен башкаруга | 16 551 |
| Башка гамәлләрне финанслауга, | 30 450 |
| шулардан: | 30 450 |
| мәгълүматлаштыру системасына ярдәм итү чыгымнарына | |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты медицина хезмәтләре күрсәтүгә түләү өчен карала торган акчалар исәбеннән күрсәтелүче медицина ярдәменең күләмен, төрләрен һәм бәясен 5 212 133 мең сум күләмендә расларга тиеш.

**28 статья.** 2002 елга Татарстан Республикасының Экология фонды бюджетын керемнәр буенча - 337 715 мең сум, чыгымнар буенча 337 715 мең сум күләмендә расларга.

2002 елда Татарстан Республикасының Экология фонды бюджеты керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән барлыкка килә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Атмосферага норматив буенча һәм нормадан тыш зарарлы матдәләр чыгарган һәм ташлаган, калдыкларны урнаштырган һәм әйләнә-тирә мохиткә башка төрле зарарлы йогынты ясаган өчен түләү | 319 006 |
| Башка керемнәр | 18 709 |

292

2002 елда Татарстан Республикасының Экология фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Әйләнә-тирә мохитне саклау буенча максатчан программаларны гамәлгә ашыруга, шул исәптән: | 313 969 |
| - Татарстан Республикасының табигатьне саклау хезмәтләре эшчәнлеген тәэмин итүгә | 71 801 |
| - Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына түләүләргә бүлеп бирү өчен | 16 886 |
| Башка чыгымнарга | 6 860 |

**29 статья.** 2002 елга Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды бюджетын керемнәр буенча - 2 973 661 мең сум, чыгымнар буенча 2 973 661 мең сум күләмендә расларга.

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды бюджеты керемнәре | 2 973 661 |

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Яңа торак йортлар салуга, шул исәптән: | 2 269 583 |
| -Тузган торакны бетерү программасы буенча | 2 019 583 |
| Төзелеш микрорайоннарында мәгариф һәм социаль-мәдәни- көнкүреш объектларын төзүгә | 115 000 |
| Коммуналь хуҗалык объектларын төзүгә | 164 078 |
| Казан шәһәре үзәген реконструкцияләүгә | 250 000 |
| Проектлау-эзләнү эшләрен финанслауга | 79 000 |
| Төзелеш индустриясе базасын үстерү гамәлләрен финанслауга | 40 000 |
| Техник инвентарьлаштыруны оештыру, чаралар җыю, идарә итү чыгымнарына | 11 000 |
| Резерв | 45 000 |

293

**30 статья.** 2002 елга Кече эшкуарлыкка финанс ярдәме буенча Татарстан республика фонды акчаларын керемнәр буенча - 116 900 мең сум, чыгымнар буенча 116 900 мең сум күләмендә расларга.

2002 елда Кече эшкуарлыкка финанс ярдәме буенча Татарстан республика фонды акчалары түбәндәге чыганаклар исәбеннән барлыкка килә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының республика бюджетыннан ассигнованиеләр | 100 000 |
| Фондтан элек бирелгән бюджет кредитларын кайтару һәм алардан файдаланган өчен түләү исәбеннән бирелә торган акчалар | 16 900 |

2002 елда Кече эшкуарлыкка финанс ярдәме буенча Татарстан республика фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Кече эшкуарлыкны үстерү буенча комплекслы дәүләт программасын финанслауга, шул исәптән: | 110 458 |
| - инвестиция проектларын финанслауга | 96458 |
| - җиһазлар лизингына | 3 000 |
| - микрокредитлар бирү фондына | 2 000 |
| - кече эшкуарлык инфраструктурасын үстерүгә, устав эшчәнлегенә | 9 000 |
| Халык художество промыселларын һәм кәсепләрен саклап калуга һәм үстерүгә | 5 000 |
| Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына түләүләргә бүлеп бирү өчен | 80 |
| Башка чыгымнарга | 1 362 |

**31 статья.** 2002 елга Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренең республика фонды (НИОКР фонды) бюджетын керемнәр буенча - 135 000 мең сум, чыгымнар буенча 135 000 мең сум күләмендә расларга.

2002 елда НИОКР фонды бюджеты керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбеннән барлыкка килә:

НИОКР фондына түләүләр буенча түләүчеләрнең вакытында түләнмәгән бурычларын туплау;

кире кайтару нигезендә бүлеп бирелгән кредитлардан һәм аларның процентларыннан керемнәр.

2002 елда НИОКР фонды акчалары түбәндәге максатларга җибәрелә:

294

инвестиция проектларын финанслауга һәм хупланган инвестиция проектлары буенча коммерциячел банклар биргән кредитларның процент ставкасы өлешен компенсацияләүгә;

Татарстан Республикасында фәннең өстенлекле юнәлешләрен үстерү программасын финанслауга;

Татарстан Республикасы Президентының Резерв фондына бүлеп бирү өчен;

НИОКР фондының устав һәм фәнни-оештыру эшчәнлеген финанслауга;

башка чыгымнарга.

НИОКР фонды акчаларын туплау һәм алардан файдалану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә, дип күрсәтергә.

**32 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы җирле бюджетларын - финанс ярдәме алучыларны тикшерергә хокуклы.

Акчаларын социаль һәм инвестиция программаларын гамәлгә ашыруга юнәлдерә торган бюджеттан тыш максатчыл республика фондларын Татарстан Республикасы республика бюджетына җибәрелә торган өлешендә салымнар түләүдән салымнар һәм җыемнар турында гамәлдәге законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә азат итәргә.

Вәкиллекле хакимиятнең җирле органнарына бюджеттан тыш максатчыл республика фондларына карата шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

**33 статья.** Татарстан Республикасының республика бюджетыннан элек бирелгән бюджет ссудаларын, бюджет кредитларын кайтарып бирү исәбеннән алына торган акчалар һәм алардан файдаланган өчен түләү Татарстан Республикасының республика бюджетына кертелә, дип билгеләргә.

Җирле бюджетлардан элек бирелгән бюджет ссудаларын, бюджет кредитларын һәм алардан файдаланган өчен түләүне кайтарып бирү өлешендә дәүләт хакимиятенең җирле органнарына шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

Бюджет кредитларын кайтарып бирү, шулай ук алардан файдаланган өчен түләү бюджетка мәҗбүри түләүләргә тиңләштерелә.

**34 статья.** Объектларны төзү, техник яктан кабат җиһазлау һәм реконструкцияләү өчен 2002 елга Татарстан Республикасының республика бюджетыннан дәүләткә карамаган коммерция оешмаларына бюджет инвестицияләре бирү әлеге юридик затларның устав (тупланма) капиталларының һәм мөлкәтләренең эквивалент өлешенә дәүләт

милекчелеге хокукын барлыкка китерә һәм Россия Федерациясенең граждан законнары нигезендә мондый юридик затларның устав (тупланма) капиталында Татарстан Республикасының катнашуы белән рәсмиләштерелә.

Дәүләт хакимиятенең җирле органнарына (җирле үзидарә органнарына) җирле бюджетлардан бирелә торган бюджет инвестицияләре буенча шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

**35 статья.** Бюджет акчаларын алучыларның акча йөкләмәләре буенча Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларын кире кайтару бурычлы затларның вәкаләтле һәм башка кредит оешмаларында ачылган счетларыннан, шулай ук Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык счетларыннан суд органнарының үтәтү кәгазьләре нигезендә гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

Бюджет акчаларын алучыларның Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык счетларыннан кире кайтарылырга тиешле акча йөкләмәләре буенча акча түләттерү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары тарафыннан суд органнарының аларга бирелгән үтәтү кәгазьләре нигезендә бары тик әлеге Законда каралган максатлар кысаларында гына Татарстан Республикасы республика бюджеты чыгымнарының ведомство, функциональ һәм икътисадый структурасы нигезендә башкарыла.

Бюджет акчаларын алучыларның акчаларын суд органнарының үтәтү кәгазьләре нигезендә исәптән төшереп калдыру, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары бәяләмәсенә таянып, гамәлдәге норматив хокукый актлар буенча әлеге статья нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык счетларыннан гамәлгә ашырыла.

Бурычлы затларның казначылык счетларында әлеге максатлар өчен акчалары җитәрлек булмаганда, үз карамагында бурычлы зат булган Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары белән төп эш йөртүче үзенә билгеләнгән ассигнованиеләр кысаларында суд карарларының үтәлеше өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә субсидиар җаваплылыкка ия була.

Бюджет акчаларын алучыларның акча йөкләмәләре буенча җирле бюджетлар акчалары исәбеннән түләттерелергә тиешле акчаларына карата шундый ук карарлар кабул итүне дәүләт хакимиятенең җирле органнарына тәкъдим итәргә.

**36 статья.** Татарстан Республикасы казнасына дәүләт хакимияте органнарының яисә аларның урындагы затларының законсыз гамәлләреннән (яки гамәл кылмауларыннан) килгән зыянны түләттерү өчен дәгъвалар буенча суд органнарының үтәтү кәгазьләре Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан башкарылырга тиеш.

296

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты суд органнарының үтәтү кәгазьләре буенча Татарстан Республикасы казнасыннан түләмнәрне закон нигезендә түләттерү тәртибен билгеләргә тиеш.

Татарстан Республикасы казнасына дәгъвалар буенча суд карарларын үтәү әлеге Законда шушы максатлар өчен каралган ассигнованиеләр исәбеннән башкарыла.

**37 статья.** Бюджет акчаларын алучыларның Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган шартнамәләрне төзүе һәм түләве алар раслаган бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында Татарстан Республикасының республика бюджеты чыгымнарының ведомство, функциональ һәм икътисадый структурасы нигезендә гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

Бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларыннан тыш, Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән үтәлә торган шартнамәләргә бәйле рәвештә бюджет акчаларын алучылар тарафыннан кабул ителгән йөкләмәләре агымдагы финанс елына Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән түләнмәскә тиеш.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары аша Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән керемнәр һәм чыгымнар сметасы нигезендә үтәлергә тиешле йөкләмәләрне исәпкә алуны тәэмин итә. Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнарының бюджет классификациясе буенча йөкләмәләрне исәпкә алырга тиешле кодлары (күрсәткечләре) исемлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

Бюджет акчаларын алучылар тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнарына исәпкә алу өчен тапшырыла торган шартнамәләрдә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнарында шартнамәләрнең исәпкә алынуы мизгеленнән башлап якларның хокуклары һәм бурычлары барлыкка килү хакындагы шарт һичшиксез булырга тиеш.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары Татарстан Республикасының республика бюджетын касса аша үтәү барышында йөкләмәләрне исәпкә алуның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртибен бозучы бюджет акчаларын алучыларның чыгымнарын түләүне туктатып торырга хокуклы.

Бюджет акчаларын алучының әлеге статья таләпләрен бозып төзегән шартнамәсе (яки аның Татарстан Республикасы бюджеты йөкләмәсен арттыруны билгели торган өлеше) югарырак оешмалар яки Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары белдерүе буенча суд тарафыннан гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин.

297

Җирле бюджетлар исәбеннән финансланучы бюджет акчалары алучылар белән шартнамәләр төзүгә карата шундый ук карарлар кабул итүне дәүләт хакимиятенең җирле органнарына тәкъдим итәргә.

**38 статья.** Татарстан Республикасының республика бюджетыннан финанслана торган бюджет учреждениеләренең эшкуарлык эшчәнлегеннән һәм табыш китерүче башка эшчәнлектән алынган акчалары Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык счетларында исәпкә алына, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасының республика бюджетыннан финанслана торган бюджет учреждениеләренең эшкуарлык эшчәнлегеннән һәм табыш китерүче башка эшчәнлектән алынган керемнәре Татарстан Республикасының республика бюджетыннан финанслана торган бюджет учреждениеләренең керемнәр һәм чыгымнар сметаларында тулы күләмдә исәпкә алына.

Вәкаләтле һәм башка кредит оешмалары эшкуарлык эшчәнлегеннән һәм табыш китерүче башка эшчәнлектән алынган акчаларны исәпкә алу буенча Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы ачкан счетларга бушлай хезмәт күрсәтә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтле һәм башка кредит оешмаларыннан Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм бюджеттан акча алучы башкаларның эшкуарлык эшчәнлегеннән һәм табыш китерүче башка эшчәнлектән алынган акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчалар турында кергән мәгълүматлар нигезендә 2002 елда әлеге акчаларның күләмнәренә һәм файдалану юнәлешләренә квартал саен анализ ясауны тәэмин итә.

Җирле бюджетлардан финанслана торган бюджет учреждениеләренең эшкуарлык эшчәнлегеннән һәм табыш китерүче башка эшчәнлектән алынган акчаларын исәпкә алуга карата шундый ук карарлар кабул итүне дәүләт хакимиятенең җирле органнарына тәкъдим итәргә.

**39 статья.** Дәүләт хакимияте һәм идарәсе җирле органнарының гарантиясе (поручительлеге) шартында Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына, предприятиеләргә һәм оешмаларга кире кайтару нигезендә бирелгән Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларын үз вакытында кире кайтармаган яисә максатчыл файдаланмаган өчен түбәндәгеләр билгеләнә, дип күрсәтергә:

- дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнарына барлык төр финанс ярдәмен бирү киметелә яки туктатыла;

- дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары бурычларын түләү Татарстан Республикасының республика бюджеты белән җирле бюджетларның әлеге Законның 19, 23 статьяларында каралган акчалар өлешендә һәм Татарстан Республикасы республика бюджетының әлеге Закон нигезендә Татарстан Республикасының җирле бюджетларына

298

күчерелергә тиешле акчалары өлешендә үзара исәп-хисап буенча түләтү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кире кайтару шарты белән бүлеп бирелгән акчаларны Татарстан Республикасының республика бюджетына кире кайтару тәртибен эшләргә һәм расларга тиеш.

**40 статья.** Дәүләт инвестицияләренә чыгымнарны финанслау 2002 елга республика инвестиция программасы һәм әлеге Законның 3 нче кушымтасы нигезендә дәүләт заказчысы исемлеге буенча гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2002 елда Татарстан Республикасының республика бюджетын үтәү барышында 2002 елга расланган күләмнәр кысаларында дәүләт капитал салулары исәбеннән төзелә торган төзелешләр һәм объектлар буенча Татарстан Республикасы республика бюджетының 2002 елның 1 гыйнварена җыелган бурычын түләүне беренче чиратта гамәлгә ашырырга тиеш.

**41 статья.** Төрле дәрәҗәдәге бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган бюджет йөкләмәләрен билгеләүче закон актларында бюджет системасы дәрәҗәләре буенча чыгымнарны финанслау чыганакларын чикләү билгеләнә.

Берләштерелгән бюджетны чыгымнарны финанслау чыганагы итеп билгеләү тыела.

**42 статья.** 2002 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән законнар һәм башка норматив хокукый актлар 2002 елда үтәлмәскә тиеш.

Әгәр закон чыгару актының һәм башка норматив хокукый актның үтәлүе бюджетта өлешчә (тулаем түгел) финанслау чыганаклары белән тәэмин ителсә, мондый норматив хокукый акт 2002 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында, җирле бюджетларда каралган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм кулланыла.

2002 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә чыгымнар таләп итүче, шулай ук аның керем базасын киметүче законнар һәм башка норматив хокукый актлар бары тик Татарстан Республикасының республика бюджетына өстәмә керемнәрнең тиешле чыганаклары булганда һәм (яисә) 2002 елга Татарстан Республикасы республика бюджетының конкрет статьялары буенча чыгымнарын киметкәндә генә, шулай ук әлеге Законга тиешле үзгәрешләр керткәннән соң гына гамәлгә ашырыла һәм кулланыла.

Башкарма хакимиятнең җирле органнарына шундый ук принципларны җирле бюджетларны үтәгәндә кулланырга тәкъдим итәргә.

299

**43 статья.** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар чыгымнарын һәм керемнәрен исәпкә алу, үтәү системасын оештыруны һәм аның нәтиҗәле эшләвен тәэмин итәргә тиеш.

Татарстан Республикасының республика бюджетын һәм җирле бюджетларны үтәү буенча исәп-хисапны касса аша башкару хезмәте күрсәтү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Бюджетларның касса аша үтәлү гамәлләрен уздыруны, комиссия түләүләре алмыйча гына, вәкаләтле банклар башкара.

**44 статья.** 2001 елда Татарстан Республикасы республика бюджетының аерым бүлекләренең тулысынча финансланмый калуы бары тик 2002 елга Татарстан Республикасының республика бюджетыннан әлеге Законның 19, 23 статьяларында билгеләнгән ассигнованиеләр исәбеннән һәм кысаларында гына компенсацияләнә.

**45 статья.** Бюджет һәм салым турындагы законнарның үтәлешен тулырак тикшереп торуны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар керемнәрен барлыкка китерүче чыганакларны тәшкил итә торган республика һәм җирле салымнар һәм җыемнар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Татарстан Республикасы республика бюджеты һәм җирле бюджетлар акчаларын исәпкә ала торган казначылык органнары счетына күчерелә, дип билгеләргә.

**46 статья.** Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты:

- 2002 елда юридик затларның үзләренә бирелгән бюджет кредитлары (ссудалары) һәм башка бурыч йөкләмәләре буенча 2002 елның 1 гыйнварена узган чор өчен Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм максатчыл бюджет фондларына бурычларын (Татарстан Республикасының республика бюджетына салымнар һәм җыемнар буенча бурычларыннан гайре) реструктуризацияләү тәртибен билгеләргә һәм үткәрергә тиеш;
- 2002 елга финанс елы чикләрендә республика салымнарын һәм җыемнарын түләү буенча салым кредитлары бирү, өлешләп түләтү, бурычны кайтаруны кичектереп тору лимитын 150 000 мең сумнан арттырмыйча билгеләргә тиеш;
- 2002 елга һәм аннан соңгы финанс елларына инвестицион салым кредитлары бирү лимитын 150 000 мең сумнан арттырмыйча билгеләргә тиеш.

**47 статья.** «Дәүләт хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 3 (отпускны уздыру урынына бару һәм аннан кайту юлы хакын түләү өлешендә), 8, 11 нче пунктлары, 15 статьясы

300

гамәлләренә бәйле чыгымнарны, элек кабул ителгән законнар нигезендә дәүләт хезмәткәрләре хезмәтенә түләү өчен, матди һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү шартлары өчен тотыла торган чыгымнардан гайре, тиешле норматив хокукый актлар кабул ителгәнгә кадәр тотмаска.

**48 статья.** Предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасының республика бюджетыннан кире кайтармау һәм кире кайтару шарты белән алынган акчаларны максатчыл файдаланмау бу суммаларны кайтарып бирү өчен һәм шушы акчаларны максатчыл кулланмау чорына Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдә булган исәпләү ставкасының икеләтә күләмендә штраф алу өчен нигез була.

Бюджет акчаларын бирү шартларында каралмаган максатларда акчаларны тота башлаган көннән Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм җирле бюджетларга кире кайтарган яисә максатчыл билгеләнештә куллана башлаган мизгелгә кадәрге чор Татарстан Республикасының республика бюджеты акчаларын максатчыл кулланмау чоры булып таныла.

Татарстан Республикасының республика бюджетыннан кире кайтару шарты белән алына торган акчаларны үз вакытында кайтармаган өчен дәүләт ярдәменең барлык рәвешләре законнар нигезендә киметелә яки туктатыла, шул исәптән салым түләүләрен кичектереп тору да туктатыла.

Бурычның төп суммасын, шулай ук Татарстан Республикасының республика бюджетыннан кире кайтару шарты белән алынган акчаларны файдаланган өчен процентларны үз вакытында түләмәгәндә, түләнмәгән һәр көн өчен Россия Федерациясе Үзәк банкының гамәлдәге исәпләү ставкасының өч йөздән бер күләмендә пеня алына.

**49 статья.** Әлеге Законны 2002 елның 1 гыйнвареннан гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 3 декабре
№ 1213